| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **ГЛАВА ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ** |

***Постановление*** ***Карар***

**31.03.2026 ел** **Чистай шәһәре** **№30**

«2025 елгы Татарстан Республикасы
«Чистай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге бюджеты
үтәлеше турында» Татарстан
Республикасы Чистай муниципаль
районы Советы карары проекты буенча
гавами тыңлаулар үткәрү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 маддәсе һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 47 маддәсе, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 16 маддәсе буенча, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 18 июлендәге, 35/5 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «2025 елгы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча 2026 елның 23 апреленә 10-00 сәгатьләрдә 18 нче кабинетта түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә: Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 17 нче йорт.
2. Фикер алышына торган проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язма рәвештә түбәндәге адрес буенча җибәрелә дип билгеләргә: Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 17 йорт, 18 нче кабинет, 5-43-70 телефоны буенча яисә электрон почта адресына – chistay@tatar.ru гавами тыңлаулар уздырган көнгә кадәр.

Тәкъдимнәр һәм кисәтүләр эш көннәрендә 8-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр (төшке аш 12-00 сәгатьтән 13-00 сәгатькә кадәр) кабул ителә.

3. «2025 елгы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы

Чистай муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетын (алга таба оештыру комитеты) түбәндәге составта төзергә:

Иванов К. В. - Чистай муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары;

Карманова Н.А. - Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе;

Хаматов Р. Г. - Чистай Выселкасы авыл җирлегеннән депутат, Чистай муниципаль районы Советының Бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

Осипов Г. Н. - Түбән Кондрата авыл җирлегеннән Чистай муниципаль районы Советы депутаты, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

Садриева И. Ш. - Чистай муниципаль районы Советының җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы;

Абзалова Л. Н. - Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы;

Гайнетдинова Р.Х. - Чистай муниципаль районының Иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча).

4. Кушу:

- оештыру комитетына күрсәтелгән карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә;

- Чистай муниципаль районының финанс-бюджет палатасына, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының Бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясенә, гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм проектны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы утырышына кертергә.

5. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә:

- әлеге карарны һәм «2025 елгы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы Карары проектын билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга;

- уздырыла торган гавами тыңлаулар буенча материалларны «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән кагыйдәләр нигезендә урнаштыруны тәэмин итәргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д. А. Иванов